СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 31 мае № 19/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законы һәм Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2011 елның 29 апрелендәге 8/7 номерлы карары (05.02.2021 № 6/9 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**37.5 пунктта** «49-55 пунктлары белән» сүзләрен «46 пункт белән, әгәр реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте кулланылганда, 49-55 пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

**46 пунктны** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«46. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү аның хуҗасы тарафыннан реклама конструкциясе кушыла торган җир кишәрлеге, бина яисә башка күчемсез милек милекчесе белән шартнамә буенча яисә мондый милекнең идарәче хуҗасы, шул исәптән арендатор белән, гамәлгә ашырыла. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдалану каралган очракта, реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән тәртиптә алынган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре ризалыгы булганда гына мөмкин. Мондый шартнамәне төзү күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы нигезендә аны төзүгә вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең

гамәлдә булу вакыты тәмамлангач, якларның килешү буенча йөкләмәләре туктатыла. Татарстан Республикасы реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә, реклама конструкцияләренең төрләренә һәм реклама демонстрациясенең кулланыла торган технологияләренә бәйле рәвештә, әмма кимендә биш елга һәм ун елга шартнамәләр төзи ала торган чик срокларны билгели. Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлегендә, бинада яки башка күчемсез милектә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең конкрет сроклары, реклама конструкциясенең тибына һәм төренә, реклама демонстрациясенең тиешле чик сроклары чикләрендә кулланыла торган технологияләренә бәйле рәвештә, муниципаль район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законы һәм гражданлык законнары нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы,Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров